КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 сентябрь г.Казань № 850

Гаиләләреннән, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларыннан, белем бирү оешмаларыннан һәм башка оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә транспортта йөртүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәртибен һәм хезмәткәрләре гаиләләреннән, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларыннан, белем бирү оешмаларыннан һәм башка оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждениеләр исемлеген раслау турында

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Гаиләләреннән, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларыннан, белем бирү оешмаларыннан һәм башка оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә транспортта йөртүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәртибен;

хезмәткәрләре гаиләләреннән, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларыннан, белем бирү оешмаларыннан һәм башка оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждениеләр исемлеген.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гаиләләреннән, балалар йортларыннан, интернат мәктәпләрдән, махсус укыту-тәрбияләү һәм башка балалар учреждениеләреннән рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә транспортта йөртүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 17 сентябрь, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 19 сентябрь, 850 нче
карары белән расланды

Гаиләләреннән, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларыннан, белем бирү оешмаларыннан һәм башка оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә транспортта йөртүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Нигезләмә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын һәм хокук бозуларын кисәтү чараларын оператив кабул итү максатларында «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның $25^1$ статьясындагы 9 нчы пункты нигезендә эшләнде һәм гаиләләреннән, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларыннан, белем бирү оешмаларыннан һәм башка оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны (алга таба – оешма, балигъ булмаган) Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә транспортта йөртүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели.

2. Балигъ булмаганнарны транспортта йөртү эшчәнлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган учреждениеләр исемлеге нигезендә балигъ булмаган аны транспортта йөртү турында карар кабул иткән көндә булган оешма (алга таба – балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждение) тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның хезмәткәрләре гаиләләреннән, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларыннан, белем бирү оешмаларыннан һәм башка оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны транспортта йөртүне башкара. Бу Тәртипнең гамәле ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учрждениеләреннән рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны транспортта йөртүне оештыруга кагылмый.

## II. Балигъ булмаганнарны транспортта йөртү тәртибе

3. Балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждение җитәкчесе яки аның башка вәкаләтле вазыйфаи заты балигъ булмаган кергән көндә балигъ булмаганның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) йә балигъ булмаган рөхсәтсез киткән оешма администрациясенә аның булу урыны турында һәм бу оешманың балаларны транспортта йөртүгә вәкаләтлеләре тарафыннан аны гаиләгә йә тиешле оешмага кире кайтару мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Оешмадан балигъ булмаганны мөстәкыйль рәвештә алып китеп һәм транспортта йөртүне гамәлгә ашырып булмау мөмкинлеге турында мәгълүмат алган яки балигъ булмаган кергән көннән соң өч көн эчендә җавап алмаган очракта, балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждение җитәкчесе балигъ булмаганны оешмага транспорт белән алып баруны гамәлгә ашыра.

4. Гаиләләреннән яки оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны аларның яшәү (булу) урынына кадәр транспортта йөртү балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждение җитәкчесе яки аның вәкаләтле хезмәткәрләре (алга таба – озатып йөрүче зат) тарафыннан балигъ булмаганны транспортта йөрткәнгә кадәр бер көн кала алар аның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) балигъ булмаганны кире кайтару турында хәбәр итү һәм алардан аны кабул итү мөмкинлеге турында раслау алу шарты белән гамәлгә ашырыла.

Гаиләсеннән йә оешмадан рөхсәтсез киткән балигъ булмаган аның яшәү (булу) урыны буенча социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсус учреждениегә түбәндәге очракларда урнаштырыла:

1) ата-аналары (законлы вәкилләре) балигъ булмаганны гаиләгә кабул итүдән баш тартканда;

2) балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждение администрациясенә 10 яшьтән зуррак балигъ булмаган тарафыннан гаиләсенә йә оешмага кире кайту мөмкинлеге булмау турында мөрәҗәгать иткәндә;

3) гаиләсендә яки оешмада 10 яше тулмаган балигъ булмаган белән рәхимсез мөрәҗәгать итү турында мәгълүмат алганда.

5. Балигъ булмаганнарны транспортта йөртү озатып йөрүче зат тарафыннан түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждениенең аны ата-аналарына (законлы вәкилләренә) яки тәрбияләнә торган оешмага кире кайтару турындагы йә аны балигъ булмаганның яшәү (булу) урыны буенча социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсус учреждениегә урнаштыру турындагы боерыгы;

2) медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча медицина оешмасы тарафыннан балигъ булмаганның транспортта йөртү көнендә сәламәтлеге торышы турында бирелгән медицина бәяләмәсе;

3) озатып йөрүче затның шәхесен таныклый торган документ;

4) балигъ булмаганны озатып йөрүче затка тапшыру акты (алга таба – акт).

6. Гаиләләреннән яки оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны яшәү (булу) урынына кадәр балигъ булмаганнарны транспортта йөртү аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) яки балигъ булмаган рөхсәтсез киткән оешма тарафыннан түбәндәге документлар нигезендә турыдан-туры гамәлгә ашырыла:

1) ата-ананың (законлы вәкилнең) шәхесен таныклый торган документны, оешма вазыйфаи затының балигъ булмаганны транспортта йөртүгә вәкаләтләрен раслый торган документны, балигъ булмаганның шәхесен таныклый торган документны (14 яше тулмаган затлар өчен туу турындагы таныклыкны) күрсәтеп, ата-ананың (законлы вәкилнең) яки оешманың балигъ булмаганны транспортта йөртүгә вәкаләтле вазыйфаи затының балигъ булмаганны яшәү (булу) урынына

кадәр илтү өчен тапшыру хакындагы үтенече белән балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждение җитәкчесе исеменә гаризасы;

2) балигъ булмаганны ата-анасына (законлы вәкиленә) яки оешманың балигъ булмаганны транспортта йөртүгә вәкаләтле вазыйфаи затына кабул итү-тапшыру акты;

3) медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча медицина оешмасы тарафыннан балигъ булмаганның транспортта йөртү көнендә сәламәтлеге торышы турында бирелгән медицина бәяләмәсе.

7. Балигъ булмаган:

1) яшәү (булу) урынына кире кайтканнан соң – ата-анасы (законлы вәкиле) балигъ булмаганның яшәү (булу) урынына кире кайткан көненнән биш календарь көн эчендә балигъ булмаганның гаиләгә кире кайтуы турында балигъ булмаганның яшәү (булу) урыны буенча халыкны социаль яклау бүлегенә хәбәр итә;

2) оешмага кире кайтканнан соң – оешма администрациясе балигъ булмаганның яшәү (булу) урынына кире кайткан көненнән биш календарь көн эчендә бу турыда балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждениегә хәбәр итә.

Балигъ булмаганның яшәү (булу) урыны буенча халыкны социаль яклау бүлеге җитәкчесе бу пунктның 1 нче пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә кергән көннән 10 календарь көн эчендә балигъ булмаган кайту турында балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждение администрациясенә хәбәр итә.

Дәүләт хакимиятенең, җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары катнашуын таләп итә торган очракларда, гаиләгә ярдәм күрсәтү яки балигъ булмаганның гомеренә һәм сәламәтлегенә потенциаль куркыныч тудыра торган шартларны бетерү максатларында, балигъ булмаганны транспортта йөртүне һәм ата-аналарына (законлы вәкилләренә) тапшыруны гамәлгә ашырган учреждение балигъ булмаганны тапшырган көннән биш календарь көн эчендә ярдәм күрсәтү һәм башка чаралар кабул итү кирәклеге турындагы мәгълүматны тиешле компетентлы органга җибәрә.

8. Балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждениедә балигъ булмаганның саклана торган әйберләре акт буенча башта озатып йөрүче затка, аннан соң оешма администрациясенә йә, раслау кәгазенә кул куйдыртып, ата-анага (законлы вәкилгә) тапшырыла.

9. Балигъ булмаганнар киткәндә тиешле сезонга туры килә торган өс киеменнән җибәрелә, аларга сезонлы аяк киеме кидертелә. Әлеге киемнәр белән аларны балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждение тәэмин итә, актка бу турыда тиешле билге куела.

Акт буенча тапшырылган өс киеме һәм аяк киеме балигъ булмаганның үзендә кала.

10. Балигъ булмаганнарны транспортта йөртү түбәндәге транспортта гамәлгә ашырыла:

а) автомобиль транспорты (йөк транспортыннан, таксидан һәм коммерция рейсларыннан тыш);

б) тимер юл транспорты;

в) су транспорты (өченче категорияле урыннарда).

11. Юлда барганда барып җитәсе урынга кадәр балигъ булмаганнар туклану, кирәк булган очракта, медицина ярдәме белән тәэмин ителә.

12. Озатып йөрүче зат балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждениегә түбәндәге документларны кертә:

1) чыгымнар турындагы аванс хисабын;

2) балигъ булмаганның һәм озатып йөрүче затның юл йөрү документларын;

3) юлда барганда балигъ булмаганны ашату һәм аңа медицина ярдәме күрсәтү чыгымнары турындагы хисап документларын;

4) балигъ булмаганны озатып йөрүче затка тапшыру актын;

5) балигъ булмаганны ата-аналарына (законлы вәкилләренә) йә оешма администрациясенә кабул итү-тапшыру актын;

6) балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждение тарафыннан, кирәк булганда, тәэмин ителгән балигъ булмаган әйберләрен йә сезонга туры килә торган аяк һәм өс киемнәреноешма администрациясенә йә ата-анасына (законлы вәкиленә) кабул итү-тапшыру акты, актка бу турыда тиешле билге куела.

13. Бер балигъ булмаганга озатып йөрүчеләр саны икедән артык кеше булырга тиеш түгел. Бердән артык балигъ булмаганны транспортта йөрткәндә озатып йөрүчеләр саны балигъ булмаганны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждение тарафыннан (балигъ булмаганнарның яшенә, юлның озынлыгына һ.б. карап) билгеләнә.

14. Балигъ булмаганны ата-анасына (законлы вәкиленә), оешма администрациясенә тапшыру озатып йөрүче зат тарафыннан балигъ булмаганны ата-анасына (законлы вәкиленә), оешма администрациясенә тапшыру акты буенча гамәлгә ашырыла, ул ике нөсхәдә, бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча төзелә.

______________________________

Гаиләләреннән, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларыннан, белем бирү оешмаларыннан һәм башка оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә транспортта йөртүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәртибенә кушымта

Форма

Балигъ булмаганны ата-анасына (законлы вәкиленә), ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмасы, балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждение яки белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешма администрациясенә кабул итү-тапшыру актына

___________________________________________________________________
(учреждение исеме)

______________________________ балигъ булмаганнар өчен махсус учреждениесе

озатып йөрүче зат __________________________________________________ йөзендә
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме булганда)

балигъ булмаган _____________________________________________________ны(не)
(фамилиясе, исеме, атасының исеме булганда)

түбәндәге атасы-анасына (законлы вәкиленә), ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмасы, балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждение яки белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешма администрациясенә тапшыра

_______________________________________________________________________
(оешма исеме)

_______________________________________________________________________
(оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________________________________________________.
(атасы-анасының (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме, туганлык дәрәҗәсе, паспорт мәгълүматлары)

Балигъ булмаган белән бергә түбәндәге әйберләр, предметлар, акча, кыйммәтләр, документлар тапшырылды: _________________________________________________

_______________________________________________________________________

Тапшырды: ______________________________ __________ ___________________
(вазыйфасы) (имзасы) (Ф.И.Ат.ис.)

Кабул итте: ____________________________ __________ ___________________
атасы-анасы (законлы вәкиле), ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмасы, белем бирү оешмасы яки белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешма администрациясе вәкиле) (имзасы) (Ф.И.Ат.ис.)

20___ ел, «___» ___________

___________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 19 сентябрь, 850 нче
карары белән расланды

Хезмәткәрләре гаиләләреннән, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар оешмаларыннан, белем бирү оешмаларыннан һәм башка оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы учреждениеләр исемлеге

| Т/с | Учреждение исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. | «Әгерҗе муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Ласка» социаль приюты» ДКУ[1] |
| 2. | «Аксубай муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Мечта» социаль приюты» ДКУ |
| 3. | «Алексеевск муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Забота» социаль приюты» ДКУ |
| 4. | «Баулы муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Семья» социаль приюты» ДКУ |
| 5. | «Бөгелмә муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Ялкын» социаль приюты» ДКУ |
| 6. | «Чүпрәле муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Теплый дом» социаль приюты» ДКУ |
| 7. | «Зеленодольск муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Гнездышко» социаль приюты» ДКУ |
| 8. | «Казан шәһәре» шәһәр округында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Гаврош» социаль приюты» ДКУ |
| 9. | «Мамадыш муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Надежда» социаль приюты» ДКУ |
| 10. | Менделеевск муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Камские зори» социаль приюты» ДКУ |
| 11. | «Минзәлә муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Тургай» социаль приюты» ДКУ |
| 12. | «Питрәч муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Шатлык» социаль приюты» ДКУ |
| 13. | «Балык Бистәсе муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Акчарлак» социаль приюты» ДКУ |
| 14. | «Саба муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Тургай» социаль приюты» ДКУ |
| 15. | «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Асылташ» социаль приюты» ДКУ |

[1]Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 5 б.

| 1 | 2 |
|---|---|
| 16. | «Түбән Кама муниципаль районында «Балалар һәм үсмерләр өчен «Балкыш» социаль приюты» ДКУ |
| 17. | «Советлар Союзы Герое Хәсән Заманов исемендәге Актаныш кадетлар интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 18. | «Карпов Павел Алексеевич исемендәге Болгар кадетлар интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 19. | «Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин исемендәге Бөгелмә кадетлар интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 20. | «Советлар Союзы Герое Николай Волостнов исемендәге Васильево кадетлар интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 21. | «К.С.Байкиев исемендәге Икшермә кадетлар интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 22. | «Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов исемендәге 82 нче кадетлар мәктәбе» ДБГББУ |
| 23. | «Советлар Союзы Герое Никита Кайманов исемендәге Кадетлар мәктәбе» ДБГББУ |
| 24. | «Калкан» полиция кадетлар мәктәбе» ДБГББУ |
| 25. | «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов исемендәге Казан кадетлар интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 26. | «Советлар Союзы Герое Михаил Алексеевич Чирков исемендәге Кама Тамагы кадетлар интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 27. | «Советлар Союзы Герое генерал-полковник Василий Николаевич Гордов исемендәге Минзәлә кадетлар интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 28. | «Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин исемендәге Идел буе федераль округының Татарстан кадетлар корпусы» ДБГББУ |
| 29. | «Генерал-майор Владимир Аверкиевич Хапаев исемендәге Тәтеш кадетлар интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 30. | «Советлар Союзы Герое И.Н.Конев исемендәге Чирмешән кадетлар интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 31. | «Советлар Союзы Герое Сергей Евдокимович Кузьмин исемендәге Чистай кадетлар интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 32. | «Иннополис лицее» ДАГББУ |
| 33. | «Иннополис мәктәбе» ДАГББУ |
| 34. | «Сәләтле балалар өчен гуманитар интернат гимназиясе» ДАГББУ |
| 35. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Әгерже интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 36. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Актүбә интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 37. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Азнакай интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 38. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Такталачык интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 39. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Әлмәт интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 40. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Рус Акташы |

| 1 | 2 |
|---|---|
| | интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 41. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 19 нчы Әлмәт мәктәбе» ДБГББУ |
| 42. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яңа Кенәр интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 43. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Бөгелмә интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 44. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Сокольский интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 45. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Бөгелмә шәһәренең 10 нчы мәктәбе» ДБГББУ |
| 46. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен Казан шәһәренең 11 нче интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 47. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Казан шәһәренең 61 нче мәктәбе» ДБГББУ |
| 48. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Казан шәһәренең 76 нчы мәктәбе» ДБГББУ |
| 49. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Казан шәһәренең 142 нче мәктәбе» ДБГББУ |
| 50. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Е.Г.Ласточкина исемендәге Казан интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 51. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Казан шәһәренең 7 нче интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 52. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Казан шәһәренең 4 нче интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 53. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Казан шәһәренең 172 нче мәктәбе» ДБГББУ |
| 54. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Казан шәһәренең 1 нче интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 55. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 67 нче мәктәбе» ДБГББУ |
| 56. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 68 нче мәктәбе» ДБГББУ |
| 57. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 69 нчы мәктәбе» ДБГББУ |
| 58. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 86 нчы «Өмет» интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 59. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 88 нче мәктәбе» ДБГББУ |
| 60. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 87 нче мәктәбе» ДБГББУ |
| 61. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 75 нче мәктәбе» ДБГББУ |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 62. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 89 нчы башлангыч мәктәбе – балалар бакчасы» ДБГББУ |
| 63. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Алабуга интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 64. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Алабуга шәһәренең 7 нче мәктәбе» ДБГББУ |
| 65. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Зәй шәһәренең 9 нчы мәктәбе» ДБГББУ |
| 66. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Зеленодольск шәһәренең 2 нче мәктәбе» ДБГГБУ |
| 67. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Мәчкәрә интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 68. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Лаеш интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 69. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Лениногорск шәһәренең 14 нче мәктәбе» ДБГББУ |
| 70. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Мамадыш интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 71. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Менделеевск мәктәбе» ДБГББУ |
| 72. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен Минзәлә интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 73. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Төйгелде интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 74. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Түбән Кама интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 75. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Югары Чаллы интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 76. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Түбән Кама шәһәренең 18 нче мәктәбе» ДБГББУ |
| 77. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Түбән Кама шәһәренең 23 нче мәктәбе» ДБГББУ |
| 78. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Нурлат интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 79. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Питрәч интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 80. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Саба интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 81. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Болгар интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 82. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Теләнче Тамак интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 83. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Татар Ялтаны интернат мәктәбе» ДБГББУ |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 84. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Чистай шәһәренең 10 нчы мәктәбе» ДБГББУ |
| 85. | «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Урыссу интернат мәктәбе» ДБГББУ |
| 86. | « Озак вакыт дәвалануга мохтаҗ булган балалар өчен Яңа Кәшер савыктыру гомуми белем бирү шифаханә интернат мәктәбе» ДБСГББУ |
| 87. | «Болгар шифаханә интернат мәктәбе» ДБСГББУ |
| 88. | «Н.А.Гәлләмов исемендәге Республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» ябык типтагы дәүләт казна махсус укыту-тәрбия бирү гомуми белем бирү учреждениесе |
| 89. | «Костер» республика балалар савыктыру-белем бирү үзәге» ДБӨББУ |
| 90. | Психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекцияләү үзәге» ДАГББУ |
| 91. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен «Әлмәт балалар йорты» ДБУ |
| 92. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен «Алабуга балалар йорты» ДБУ |
| 93. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен «Лаеш балалар йорты» ДБУ |
| 94. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен «Лениногорск балалар йорты» ДБУ |
| 95. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен «Түбән Кама балалар йорты» ДБУ |
| 96. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен «Нурлат балалар йорты» ДБУ |
| 97. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен «Чистай балалар йорты» ДБУ |
| 98. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен «Идел буе районы балалар йорты» ДБУ |
| 99. | «36 нчы кичке (сменалы) гомуми белем бирү мәктәбе» ДКББУ |
| 100. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» ДАББУ |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

ДАГББУ – дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе;
ДБСГМУ – дәүләт бюджет савыктыру гомуми белем бирү учреждениесе;
ДБГББУ – дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;
ДБУ – дәүләт бюджет учреждениесе;
ДБӨББУ – дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе;
ДКББУ – дәүләт казна белем бирү учреждениесе;
ДКУ – дәүләт казна учреждениесе.

___________________________